**СОВЕТ КИРБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422626 с. Кирби,
ул. Лесная, д.1а
тел: 4-38-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХӘЕРБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422626 Хәерби авылы,
Урман урамы, 1а нчы йорт,
тел: 4-38-16

---

**2021 елның 22 декабре** **102 номер**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең Травкино торак пунктында гражданнар җыены карары.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең Травкино торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2022 елда Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2022 елда үзара салым акчаларын 5000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә дигән карарны-

--- Травкино торак пунктында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту (Озерная урамы, ташу, вак таш һәм ком җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).дөрес дип танырга .

3. Әлеге карарны Хәерби авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче: _______ М.Д.Минбаева**

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Хәерби авыл җирлеге**
**Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы ______ М.Д.Минбаева**